


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 12 (27) 22 ИЮНЯ 2010



# Встреча на Оренбургской земле

Как уже сообщалось в средствах массовой информации, 15 июня состоялось торжественное вступление в должность нового Губернатора Оренбургской области Юрия Берга. На это мероприятие прибыл Премьер-министр Республики Татарстан Ильдар Халиков. Вместе с ним Оренбург посетил Председатель исполкома Всемирного конгресса татар Ринат Закиров.

Высоких гостей в аэропорту встречали депутаты Законодательного Собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов и Ильдар Насыбуллин, а также и.о. заместителя председателя Правительства — министра сельского хозяйства, пищевой и перерабатывающей промышленности Оренбургской области Сергей Соловьев.

Гости из Татарстана побывали в татарском драматическом театре имени Файзи и встретились с представителями национальной общественности оренбуржья.

Ильдар Шафкатович Халиков в своем выступлении выразил надежду, что новый губернатор области станет больше внимания уделять проблемам татар проживающих в регионе и способствовать развитию их культуры, языка, традиций.

Гости привезли с собой подарки, в свою очередь оренбуржцы тоже не остались в долгу. И. Давлятов и И. Насыбуллин вручили Премьер-министру и председателю ВКТ оренбургские пуховые платки и памятные книги.

Затем гости отправились на церемонию инаугурации Губернатора Оренбургской области.

**На снимке:** И.Давлятов, С.Соловьев, И.Халиков, И.Насыбуллин.

# Үзебезнең гәзитебез

Шушы көннәрдә, барлык почта элемтә бүлекләрендә 2010 елның икенче ярты еллыгына гәзит һәм журналларга язылу кампаниясе бара. Матвеевка районы Иске Әшер авылы почта мөдире Нәсимә Миннәхмәт кызы Гомәрова әйтүе буенча, авыл халкы күмәк басмаларга языла.

Иске Әшер авылы халкы арасында "Атна", "Юлдаш" гәзитләрен халык түземсезлек белән көтеп ала. Үзебезнең яраткан "Туган як" гәзитен дә авылдашлар сөенеп укый. Аның язылу хакы да бик арзан: нибары 94 сум 500 тиен генә.

Әммә, гәзит битләреннән укып, таң калдык: нишләп үзебезнең төбәктә чыгып килгән, бердән-бер татар гәзитенә почта хезмәткәрләре язылуны тоткарлыйлар икән? Нишләп гәзитнең язылу хакында почта бүлекләренә бик соңлап кына иглан иткәннәр?

Үзебезнең татар телендә чыгып килгән гәзиткә каршы килү, бу хакта дөрес нәрсә түгел.

Киләсе язылу кампаниясендә мондый аңлашылмаучылык булмас дигән ышанычта каласы килә.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**

ВЕСТИ. СОБЫТИЯ. РЕПОРТАЖИ

# САБАНТУЙЛАР ҖИТСӘ, ГОРУРЛАНАМ ХАЛКЫМ БЕЛӘН

Ил буйлап сабантуйлар атлый. Менә инде Әсәкәй районына да чират килеп җитте. Җәйнең ямьле бәйрәме биредә 12 июньдә үтте. Бу көнне дәүләтебездә Рәссәй көнен билгеләп үттеләр, ә әсәкәйләр, аннан башка Район көнен һәм хезмәт туен да бәйрәм итте. Милләтнең күркәм бәйрәмнәрнең берсе интернациональ бәйрәмгә әйләнеп барабара, үзенчәлеген югалтмый микән соң? Күпмилләтле Әсәкәй халкы моңа тәгәл җавап бирә. Һәм ул нәкъ шушы көндә ачыкланды.

Бәйрәмне район башлыгы Николай Макаров ачып җибәрде, эстафетаны татарлар башкаласыннан килгән атаклы шәхесләр дәвам итте. Әсәкәй халкын бәйрәм белән котлар өчен Татарстаннан зур кунаклар килгән иде. Бөтендөнья татарлар конгрессының башкарама комитеты вәкиле Гөлназ Шәйхи һәм Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Сәләхов әсәкәйләрне котлап, Казаннан күп сәламнәр алып килгән иде.

Халык үзенең уңган халык икәнен эш һәм бәйрәм белән исбатлый ала. Язгы җир эшләре тәмамлангач, бераз уйнап алырга да мөмкин.

Сабантуйның күркәм күренешләре — ат чабышы белән милли көрәш. Ата—бабаларыбыз рухын саклаган бу бәйгеләр милләтебезнең көчен, тырышлыгын күрсәтә. Бәйрәм атлар чабышыннан башланып китте.

Ат ярышын кем караган, аның күңелендә дә чабышкы ат бии диләр. Җырсыз, биюсез сабантуй булмый. Шуңа күрә дә сәхнә кырыена гадәттәгечә күп халык җыела. Ак яулыклы апалар, төбәтәй кигән абыйлар, кечкенә балалар да татар моңына битараф кала алмый. Биредә Виолетта Валишина, Ришат Мухаметзянов, Элеонора Дәүләтова, "Чишмә" ансамбеле кебек Әсәкәй йолдызлары чыгыш ясады. Яковлевка, Рязановка, Солтангол авылы җыр осталары да үз сәләтләрен күрсәтмичә калмады.

Казаннан килгән моңлы тавышлы кунаклар бәйрәмгә ямь өстәде. Рөстәм Закиров Әсәкәйгә беренче килми инде. Тамашачыга да ул күптәннән таныш, аның җырлары халыкка бик якын. Казаннан тагын бер кунак — яшь җырчы Гөлгенә Калимуллина. Ул үзенең көчле тавышы белән барлык килгән халыкны таң калдырды. Гөлгенәгә дә безнең тамашачы бик ошады: җырларына кушылып җырлаулары, сәхнә түренә менеп биюләре кызга хуш килде.

Әсәкәй сабантуйның үзенчелекләрнең берсе — милли ихаталар. Районда татулыкта, дуслыкта бик күп милләт яши. Шуларның мәдәниятләре белән таныштырган бәйге сабантуй кунакларына бик охшаш. Ел саен бу "әйләр" янына бик күп кеше җыела: берсе фотога төшә, икенчесе чигүләр карый, өченчесе пешә-пешә кайнар чәй эчеп утыра. Заглядин, Иске Мөәмин, Солтангол, Красная Горка, Чкалово, Лекаревка, Карамал авыллары һәм "Чишмә" ансамбеле осталары үз кунакчылыгын күрсәттеләр. Казах, чуваш, мордва, рус, татар халыкларының ничек яшәгәнен, йортларын ничек җыештырганын биредә күрсәтелгән иде. Тәрәзәдә — чигелгән сөлгеләр, идәндә — суккан паласлар, өй түрендә — бишек, өстәлдә — милли ризык, хуҗабикәләрнең йөзләрендә — ягымлы елмаю. Ә ихата түрендә самавыр кайнап утыра, авыз суларын китерерлек пылау пешә.

Жюри әгъзаларына иң яхшыларын сайлап алырга бик кыен булды. Әммә, бәйге — бәйге инде ул. Нәтиҗәдә, иң күркәм ихата — район мәдәният йорты әзерләгән каралтысы булды. Мондый чараларның зур мәгънәсе — алар милләткә югалмаска ярдәм итә, әби — бабайларыбыздан калган йолаларны саклап калырга көч бирә.

Батырлар көрәш келәменә җыела. Мәртәбәле хөкемдәрләр иң көчлесен, иң уңганын, иң тапкырын алар арасыннан сайлап алырга тиешләр. Кыскасы, баш бүләккә ия булган көрәшчене билгеләргә кирәк була. Сабантуй батырын быел «ВАЗ-2107» машинасы көтеп тора иде. Аны бүләк итеп куярга "Алга" АҖ, Ришат Галимов- крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы, Әсәкәй нефть компаниясе, Әлмәттән "Ямбулойл" җәмгыяте зур ярдәм күрсәттеләр.

Һәм ниһаять, мәйданда көрәш башланып китте. Җыелган тамашачылар монда килүләренә бердә үкенмәгәннәрдер дип ышанасы килә. Көчле егетләр, матур алымнар җан атучыларны кызыра гына барган. Быел көрәшүчеләр арасында бер кыз да пәйда булды. Малайларга чакыру биргән Луиза Сөләймановага җыелган халык тел шартлатып карадылар. Кызганычка каршы финал ярышында кыз беренчелекне Петр Луценковка бирде. Тамашачылар малайны джентельмен адымга бик үгетләсәләр дә, Петя үз авырлыктагы үлчәүләрдә батыр исемен ия булды.

Балаларга да, аксакалларга да көрәш мәйданында урын табылды, әммә, бил алышуны карарга килгәннәр абсолют батырын билгеләүче ярышларын көтеп алды.

Нәтиҗәдә, машинага утырып китүче батыр — Заглядин егете Алибек Ахметов булды. Беренчелек өчен ул Артем Горбенко белән көрәште. Артем бик нык каерышса да, данлыклы Алибек бер алым белән генә, чиста җиңүне яулап алды. Өченче урын бүләкләрен Ахметовның авылдашы Георгий Боярков алып китте.

Көрәш мәйданыннан бераз читтәрәк кул көрәштерделәр, гер күтәрделәр, баганага мендeләр. Биредә дә иң көчлеләрне бүләксез калдырмадылар. Әммә, элек-электән безнең халык мал өчен түгел, ә дан өчен көрәште. Киләчәктә дә алай булыр дигән өметтә каласы килә.

Соңгы вакытта сабантуй бетә дип, зарланучылар артты. "Сабантуй миллелеген югалта", "Спорт бәйгесенә әверелеп бара", — диючеләр дә күп. Әйе, Алтын Урда чоры сабантуе 21 гасыр сабантуе белән чагыштырып та булмый, ләкин бәйрәмнәр уздырыла, татар халкы аңа җыела. Менә Әсәкәй җирендә дә хезмәт туе инде 19 тапкыр үткәрелде. Киләсе елларда да туганнар җыелышып, бәйрәм итеп, күңелләрне күтәреп сабантуйлар дәвам итсә иде.

**Алсу ХАФИЗ.**

БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# КҮҢЕЛЛӘРГӘ РӘХӘТ БИРДЕҢ, САБАН ТУЕ!



***Сабан туе килә, сабан туе,***
***Шау-гөр килә урман — тугае.***
***Җырлап торсын тальян***
***гармуннары,***
***Котлап торсын***
***сабан туйлары!***

"Эш беткәч уйнарга ярый", — дип халык белмичә әйтмәгәндер инде. Язгы чәчүләр — ул иң мөһим эшләрнең берсе, чөнки алдагы салкын кышларда тукланасы бар әле. Һәр кемгә таныш, борынгыдан килгән бәйрәм, шул әһәмиятле эшнең бетүен билгели. Шуңа күрә, Сабантуйны сагынып көтеп алалар. Солтангол авылында Сабантуй әләме 5 июнь көнне күтәрелде.

Ә бәйрәм алдыннан Иске Солтангол авыл клуб эшчеләре халкыбызның күркәм йоласын искә төшереп, авыл урамнарыннан гармун тартып авылдашларын бәйрәмгә чакырып, батырларга бүләк җыеп әйләнеп чыктылар.

Ташлы тау итәгендә, киң болынлыкта урнашкан Сабантуй мәйданына иртәннән бирле халык агыла башлады. Сату нокталары үз эшләрен башлаган иде, ә менә тантаналы ачылуны бераз көтәргә туры килде. Һәрбер татар чаралары, әлбәттә, дин вәкилләреннән башлана. Солтангол сабантуенда да Корбанай имам—хәзрәте — Харис Сулейманов ачып җибәрде. Соңыннан үзләренең сәламләү сүзләрен "Алга" акционер җәмгыятенең генераль рәисе Ильдус Давлятов, Яңа Солтангол авыл хакимиятенең җитәкчесе Ягфар Фаттахов һәм Әсәкәй район башлыгы Николай Макаров әйтеп үттеләр. Язгы чәчү йомгаклары белән Рәис Хазиахметов таныштырып китте, ә инде алдынгы эшчеләрне Ильдус Давлятов үзе бүләкләде. Алар арасында Рушания Кутдусова һәм Фәрит Шарипов мактаулы хокукка ия булдылар — алар быел сабантуй әләмен күтәрделәр.

"Алга" акционер җәмгыятенең генераль рәисе Ильдус Давлятов әйтүе буенча, язгы чәчүләр уңышлы гына тәмамланып бетте. Йөздән артык гектар җир чәчелеп бетте. Кыр эшләрен бетергән эшчеләргә хәзер яңгырны гына көтәргә кала.





***Ераклардан ак сөлгесен***
***болгап,***
***Чәчкләрен сибеп туфракка.***
***Хөрмәтләргә халкын —***
***яшен, картын —***
***Сабан туе килде кунакка.***

Сәхнәдән моңнар агыла. Быел Солтангол сабантуена күрше республикадан кунаклар килде. Башкортостан артистлары Фәрида һәм Роберт Тимербаевлар буш кул белән килмәде, безнең авылга багышланган җыр алып килделәр. Якын күршеләр дә Кинәле буендагы бәйрәмне онытмадылар: "Чишмә" ансамбеле үзләренең күңелле биюләрен күрсәтте, ә сәхнә ветераны Галия Калимуллина килгән һәрберсен позитив белән тутырып китте. Алсу Галимуллина, Ришат Мухаметзянов кебек яшь талантлар тамашачы күңеленә хуш килде дип ышанабыз. Гомумән, концерт программасын Альфира Мугинова, Ильдус Абдрахманов һәм Гөлчирә Хаирова алып бардылар.

Җыр сөючеләр сәхнә янына якынрак килеп карадылар, ә батырлар үз көчләрен сынадылар. Беренчедән булып, ат чабышы уздырылды. Үзләренең тугры атларын күрсәтер өчен, Солтангол сабантуена Гали авылы, Чеганлы авылы, әлбәттә, "Алга" акционер җәмгыяте вәкилләре җыелды. Быел атлар чабышында рысаклар, эш атлары, ике яшьлек атлар, һәм ике яшьтән карт атлар көч сынашты. Иң зур бүләкләрне Гали авылы кызы Н. Щербинина һәм Чеганлы егете И. Хабибуллин алып киттеләр.

Сабантуйның борынгыдан калган бәйгеләрнең берсе — тауга каршы чабу. Иң тиз йөгерүче Солтангол авыл егете — Руслан Зиганшин булды. Атлар чапкан кругта да ул беренчелекне яулап алды һәм өйгә ике тузан суырткычын күтәреп кайтып китте. Иң көчле егет гир күтәргән урында билгеләнде. Ул Руслан Зиганшинның авылдашы — Айнур Вафин булды.

***Сабан туе — көрәш туе,***
***Сабан туе — ярыш туе,***
***Егетләрдә гайрәт, көч бар.***
***Батырларга сайрый кошлар.***
***Батырларны сайлый кызлар.***

Сабантуйда һәркем үзенә хуш килгән уеннар, бәйгеләр таба ала, ләкин бу бәйрәмнең йөзек кашы булып саналган милли көрәш һәрвакыт тамашачыларны үзенә тарта.

Сабантуй көрәшен дайми күзәтеп баручыларга быелгы көрәшүчеләр таныш иде: ул Заглядин, Әсәкәй, Богырслан һәм Солтангол җирләрендә үскән батырлар. Аларга әзерләгән бүләкләр шәптән булды: суыткыч, телевизор һәм тузан суырткычтан башка, Сабантуй батырын сарык бәрәне көтеп тора иде.

Дүрт сәгатькә якын дәвам иткән көрәш бәйгесе тәмамлангач, төрле авырлыктагы үлчәүләрдә җиңүчеләр дә билгеле булды. Балалар көрәш бәйгесенә йомгак ясап, алты авырлык үлчәвендә беренче урыннар шулай бүленде: 1996-2000 елларда туган арасында: Богырыслан егетләре Айрат Самигуллин һәм Илдар Халяфутдинов һәм Заглядинодан Руслан Ахметов беренче урынларга ия булдылар. 1992-1995 елларда туганнар арасында Талгат Зиятдинов, Халадин Мамедов һәм Петр Луценков өйләренә өр-яңа караоке дивиди — плеер алып киттеләр. Зур һәм тәҗрибәле батырлар арасында иң көчлеләре булып Алибек Ахметов һәм Рифат Лутфуллин булдылар. Менә бу ике егет сабантуй батыры исеме өчен көрәштеләр. Ахырында, иңнәренә тәкә күтәрүче, Алибек Ахметов булып чыкты. Ул соңгы ярышта үз көндәшен бер алым белән генә келәмгә алып салды.

***Күңелләргә рәхәт бирдең,***
***сабан туе!***
***Рәхмәт сиңа, рәхмәт,***
***гүзәл сабан туе!***

Матвеевка районнынан килгән кунакларның рәхмәт сүзе сабантуйның күркәм ноктасы булып калды. Күршеләр Ильдус Давлятовка бәйрәмне оештырган өчен һәм авылларындагы клуб ишеген ачарга ярдәм иткән өчен, чиксез рәхмәтләрен белдерделәр. Шулай итеп, язгы чәчү бәйрәме халык күңелендә бары тик якты хис һәм туган җиренә мәхәббәт уятты. Ләкин, Сабантуебызның халык бәйрәме булып барлыкка килгәнен онытмаска кирәк. Элек — электән эшләп арыган халыкның бер тапкыр уйнапкөлеп, сагынып сөйләрлек бәйрәме ул Сабантуй.




**Алсу ХАФИЗ.**

**На фото:** моменты сабантуя.

**Фото автора.**

БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# "АК КАЕНДА" БӘЙРӘМ

**Курчак кебек киенгән кечкенә кыз балалар һәм малайлар Науруз авылының "Ак каен" балалар бакчасында 10 июньдә үткәрелгән тантананың сәбәпчеләре булдылар. Бу әмәл 25 баланың чыгарылышына багышланган иде.**

Алар аңа тәрбияләүчеләр белән озак кына әзерләнгәннәр. Театраль чыгышка килгән әниләренә, әбкәйләренә алар үзләренең һөнәрләрен күрсәттеләр. Яшерелмәгән куаныч белән кунаклар балаларның чыгышын карадылар. Куанырлык та шул. Кыюланып кечкенә артислар үзләренең бию, матур итеп җырлаулары белән генә сокландырмадылар. Алты-җиде яшь тулган бөләкәчләр уку, язу, санау белүен җитез итеп күрсәттеләр. Әйтеп үтәргә кирәк, чыгышны алар чиста рус телендә үткәрделәр. Бу мактаулы очрак. Татар телен алар бит бишектән үк аңнап, ана сөте белән үзләренә сеңдергәннәр. Үз теле алар өчен беренче булып тора.



Балалар оешма программасы буенча "Ак каен"да кечкенәләр белән рус телендә эш алып барыла. Шулай итеп алар мәктәптә укуга әзерләнәләр. Беренче класска барганда алар бу телне белергә тиешләр, чөнки мәктәп милли түгел бит.

Шулай да, татар теле балалар бакчасында ин мөһиме — үз телендә кечкенәләр белән төп аралашу. Программадан тыш алар белән татар телендә дәресләр алып баралар. Ата-аналары телендә кечкенәләр өчен бәйрәмнәр үткәрелә, алар концертларда татар телендә чыгыш ясыйлар. Шуңа күрә татар җырларын, такмакларын, биюләрен өйрәнәләр. "Ак каенда" эшләгән апалары алар өчен костюмнар теккәннәр. Көн саен балалар белән эш татар телендә бара. Балалар бакчасы эмонциональ юнәлеш буенча эшләгәнгә күрә кечкенәләр кешеләрнең эмоцияларын татар телендә дә өйрәнәләр. Ял минутларында аларга апалары әкиятләр укыйлар. Убырлы Карчык, Шүрәле персонажларын алар бик яхшы беләләр. Әкияттә ялган булса да, егетләргә бит анда үрнәк күрсәтелгән. Нинди батыр булып үсәргә тиеш татар егете, сылу татар кызы. Моның турында балалар апалары белән тикшерәләр. Балалар бакчасында татар телендә китаплар җитәрлек дип әйтергә була, Казаннан алып кайтып торалар, бүләк тә итеп бирүчеләр бар.



Бакча эчендә "Халкыбызның күңел бизәкләре" темасына почмак бизәлгән. Анда татар халык иҗаты күрсәтелгән. Бу почмак янында балалар көндә карап үтәләр, ихтибар итәләр.

"Бу елны чыгарылган балалар бик гипер активлы, кызыксынучанлыклар, мәктәптә яхшы укып, яхшы кешеләр булып үсәрләр дип ышанам",- дип әйтә "Ак каен" җитәкчесе Хәсинә апа Ахметшина.

Аның сүзләре нигезсез түгел. Балалар ике телдә иркеле рәвештә сөйләшәләр. Ике телне белгән кеше өченчене дә җиңел итеп өйрәнә диләр. Барлык фәннәрдән дә өлгерү курсәтәләр. Шулай булгач, аптырарлык түгел инде Науруз мәктәп укучыларына. Алар арасыннан табибләр, укытучылар, юристлар чыга. Аларның һәркайсы үз телен белеп, үз телен яратып, татар иқәнен горурланып яши.

**И.СУЛЕЙМАНОВА.**
**Пономаревка районы.**

# Эшемә дәрт бирде

2010 ел — Рәсәй Президенты Д.А. Медведев Указы тарафыннан, безнең илдә укытучы елы дип иглан ителде. Шушы тарафтан, тәрбиячеләр һәм белем бирүчеләргә күп бәйгеләр үткәрелә.

18 гыйнвардән 8 апрельгә кадәр М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү югары белем алу йортында һәм фән белем бирү министрлыгы рус теле һәм әдәбият укытучылары арасында конкурс үткәрелде. Бу бәйгедә барлыгы 200 мәктәп укытучылары, 100 артык көллият педагоглары катнашты. Шулар арасыннан, Лида Дамир кызы Хәмидуллина Матвеевка районы Иске Котлемәт мәктәбенең рус теле һәм әдәбият укытучысы конкурста катнашып, җиңүгә лаек булды. 14 майда бөтен җиңүчеләр Мәскәүгә чакырылды. Лида Дамировна әйтүе буенча, тантана бик күңелле үтте. Барлык укытучылар белән филологлар түгәрәк өстәл үткәрделәр, җиңүчеләр алдында профессорлар чыгыш ясады. Ә аннан соң, кунаклар концертларга, экскурсияләргә барды. Алар бик күңелле үтте, дип сөйләде Л.Д. Хәмидуллина.

"Шушындый очрашулардан соң күңелләр күтәрелеп, тагын да үзсмнең яраткан эшемә дәрт кереп кайтты. Зур рәхмәт Матвеевка районы белем бирү бүлегенә, җитәкчесе Марс Рашитович Шагатдиновка, шушы тантанага баруда зур ярдәм күрсәткән өчен",- дип сүзен тәмамлады Л.Д. Хәмидуллина.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**

# Сәнгать яратучылар

Фәния Исрафил кызы Калимуллина Матвеевка районы Иске Котлемәт авылында туып үсә. Аны әнисе кешегә карата ихтирамлы, ярдәмчел, изге күңелле булырга тәрбияләп үстерә. Ул кечкенә чагыннан җырга гашыйк була, шигырьләр яратып укый. Иске Котлемәт урта мәктәбен тәмамлагач Оренбург культура училищесына укырга керә һәм уңышлы тәмамлап туган авылында методист булып клубта эшли башлый. 1985 елны Фәния апа Иске Әшер авылы егетенә Гакиль Гакифович Калимуллинга кияүгә чыга һәм дүрт кыз тәрбияләп үстерәләр. Бүгенгесе көндә Калимуллиннар гаиләсе Матвеевка авылында яшиләр. Гакиль абый коммуналь хуҗалыгында эшли, ә Фәния апа администрациядә вахтада утыра. Әниләренә охшап ике кызлары Флорида белән Гелия Оренбургның культура көллиятен бетереп, кулларына диплом алып чыгалар. Әлегесе көндә олы кызлары Флорида гаиләсе белән Иске Әшер авылында көн күрәләр һәм ике ул үстерәләр. Икенче кызлары Гелия район китапханәсендә эшли, Гөлчәчәк Бугурусланда педагогия көллиятендә укый. Ә кечкенәләре Гүзәл 10 сыйныфны яхшы билгеләргә генә тәмамлады. Барысы да җырларга яраталар, пианинода уйныйлар. Флорида белән Гүзәл җидееллык район музыка мәктәбен тәмамладылар һәм үзләренең гүзәл тавышлары белән халыкларны сөендерәләр. Алар кул эшләрендә дә осталар: чигергә, бәйләргә һәм әниләре кебек матур гөлләр үстерергә яраталар.

Фәния апа буш вакытларында шигырь язарга ярата. Өч шигыре "Туган як" гәзитендә басылып чыкты. Район мәдәнияте өчен җан атып йөри ул. Менә шундый гаиләләрнең берсе булып тора Калимуллиннар гаиләсе. Алдагы көннәрендә мин аларга озын гомер, сәламәтлек, ак бәхетләр телим.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное, летнее)

| июль | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 2 | 5-04 | 6-04 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 3 | 5-05 | 6-05 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 4 | 5-06 | 6-06 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 5 | 5-07 | 6-07 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 6 | 5-08 | 6-08 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 7 | 5-09 | 6-09 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 8 | 5-10 | 6-10 | 15-10 | 21-05 | 23-05 | 24-35 |
| 9 | 5-11 | 6-11 | 15-10 | 21-04 | 23-04 | 24-34 |
| 10 | 5-12 | 6-12 | 15-10 | 21-03 | 23-03 | 24-33 |
| 11 | 5-13 | 6-13 | 15-10 | 21-02 | 23-02 | 24-32 |
| 12 | 5-14 | 6-14 | 15-10 | 21-01 | 23-01 | 24-31 |
| 13 | 5-15 | 6-15 | 15-10 | 21-00 | 23-00 | 24-30 |
| 14 | 5-16 | 6-16 | 15-10 | 20-59 | 22-59 | 24-29 |
| 15 | 5-17 | 6-17 | 15-10 | 20-58 | 22-58 | 24-28 |
| 16 | 5-18 | 6-18 | 15-10 | 20-57 | 22-57 | 24-27 |
| 17 | 5-19 | 6-19 | 15-10 | 20-56 | 22-56 | 24-26 |
| 18 | 5-21 | 6-21 | 15-10 | 20-55 | 22-55 | 24-25 |
| 19 | 5-23 | 6-23 | 15-10 | 20-54 | 22-54 | 24-24 |
| 20 | 5-25 | 6-25 | 15-10 | 20-52 | 22-52 | 24-22 |
| 21 | 5-26 | 6-26 | 15-10 | 20-51 | 22-51 | 24-21 |
| 22 | 5-27 | 6-27 | 15-10 | 20-50 | 22-50 | 24-20 |
| 23 | 5-28 | 6-28 | 15-10 | 20-49 | 22-49 | 24-19 |
| 24 | 5-30 | 6-30 | 15-10 | 20-47 | 22-47 | 24-17 |
| 25 | 5-32 | 6-32 | 15-10 | 20-45 | 22-45 | 24-15 |
| 26 | 5-33 | 6-33 | 15-10 | 20-44 | 22-44 | 24-14 |
| 27 | 5-34 | 6-34 | 15-10 | 20-43 | 22-43 | 24-13 |
| 28 | 5-36 | 6-36 | 15-10 | 20-41 | 22-41 | 24-11 |
| 29 | 5-38 | 6-38 | 15-10 | 20-39 | 22-39 | 24-09 |
| 30 | 5-40 | 6-40 | 15-10 | 20-37 | 22-37 | 24-07 |
| 31 | 5-41 | 6-41 | 15-10 | 20-36 | 22-36 | 24-06 |

Данные предоставлены Бугурусланской мечетью. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут. (Время летнее).

# ҖИҢҮ КӨНЕНӘ



Сугыш сүзе биш хәрефтән генә,
Ә мәгънәсе нинди куркыныч.
Сугыш аркасында ничә еллар буе
Халык йөрәгендә моң, сагыш.

Тагын ничә еллар төзәлмәсләр,
Сугыш салган тирә яралар.
Һаман авыр сулый ата йөзен,
Күрми калган газиз балалар.

Әтием нинди иде? — дигән сорау,
Телгәли бит ана бәгырен.
Тыныч тормыш шундый күңелле бит,
Белеп яшик аның кадерен.

Күңел төшенкелегенә бирелмичә,
Киләчәккә өмет тудырыйк.
Татулыкта, бәхет дулкынында,
Шат тирбәлеп гомер уздырыйк.

**Мәбрүрә ХАИРОВА,**
**Иске Солтангол авылы.**

## «Туган як» — газета твоего родного края!

**До 10 июля продлена подписка на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» на второе полугодие 2010 года.**

Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.

**Подписаться можно в любом почтовом отделении или непосредственно у почтальонов.**

Индекс издания 53167. Цена за полугодие – 94 рубля 50 копеек.

**Справочные телефоны в Асекеево: 8-(353-51) 2-22-81 или 8-9325307333.**

## ОБЪЯВЛЕНИЯ

Редакция газеты «Туган як. Родной край» готова на взаимовыгодных условиях **сотрудничать** с **рекламодателями** и по их заказу готовить и публиковать тематические статьи и материалы.

**Уважаемые подписчики газеты!** Редакция принимает заявки на публикацию поздравлений, благодарностей и объявлений, в том числе и на татарском языке. Так как газета выходит два раза в месяц, просим делать заявки заблаговременно. Справки по телефонам **8 (353-51) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

Редакция «Туган як. Родной край» с благодарностью **примет спонсорскую помощь** от организаций и частных лиц для издания газеты. Справки о банковских реквизитах по телефонам **8 (35351) 2-22-81** или **8-93-25-30-73-33.**

## ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

**22 ИЮНЯ, ВТОРНИК**
Ночью +13. Днем +239. Ясно. Без осадков.

**23 ИЮНЯ, СРЕДА**
Ночью +15. Днем +31 . Ясно. Без осадков.

**24 ИЮНЯ, ЧЕТВЕРГ**
Ночью +16.Днем +33. Временами облачно. Без осадков

**25 ИЮНЯ, ПЯТНИЦА**
Ночью +19. Днем +35. Ясно. Без осадков

**26 ИЮНЯ, СУББОТА**
Ночью +20. Днем +31. преимущественно ясно. Без осадков

**27 ИЮНЯ, ВОСКРЕСЕНЬЕ**
Ночью +18. Днем +28. Ясно. Без осадков.

**28 ИЮНЯ, ПОНЕДЕЛЬНИК**
Ночью +21. Днем +36. Ясно Без осадков.

**29 ИЮНЯ, ВТОРНИК**
Ночью +21. Днем +31. Ясно. Без осадков

**30 ИЮНЯ, СРЕДА**
Ночью +19. Днем +31. Облачно. Без осадков



## ПРОГРАММА ТНВ ТАТАРСТАН

ВРЕМЯ МЕСТНОЕ

### 22 ИЮНЯ, ВТОРНИК

08-00 Хэерле иртэ!
10-00 Доброе утро!
11-00 Приключения мага. (2-я серия)
11-45 КГТУ: путь к профессии
12-00 Жырлыйк эле
12-45 Колкеханэ
13-00 ТВ фондыннан
13-30 Халкым минем...
14-00 Эдера. (1-я серия)
15-00 Один день из жизни войны
15-15 Р. Харис. «Выставка Победы-1975»
15-30 Природа у вас дома
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Яшьлэр тукталышы
17-15 Классная работа
17-30 Музыкаль NON-STOP
17-50 Т. Миннулин. «Саташу».
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (2-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Концерт-реквием
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Туган жир
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 КГТУ: путь к профессии
00-05 Приключения мага. (2-я серия)
01-00 Что сказал покойник. (8-я серия)
02-00 Автомобиль

### 23 ИЮНЯ, СРЕДА

08-00 Хэерле иртэ!
10-00 Доброе утро!
11-00 Приключения мага. (3-я серия)
11-45 КГТУ: путь к профессии
12-00 Ватандашлар
12-30 Концерт
13-00 Китап
13-30 Яшэсен театр!
14-00 Эдера. (2-я серия)
15-00 Среда обитания
15-30 Природа у вас дома
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Син - минеке, мин - синеке
17-15 Мультфильмнар
17-30 Музыкаль тэнэфес
17-45 И. Мэхмутова. «Син бит минем бергенэм...»
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (3-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Истории золотых лихорадок
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Кара-каршы
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 КГТУ: путь к профессии
00-05 Приключения мага. (3-я серия)
01-00 Что сказал покойник. (9-я серия)
02-00 Видеоспорт
02-30 Истории золотых лихорадок

### 24 ИЮНЯ, ЧЕТВЕРГ

08-00 Хэерле иртэ!
10-00 Доброе утро!
11-00 Приключения мага. (4-я серия)
11-45 КГТУ: путь к профессии
12-00 Кэеф ничек?
13-00 Үткэннэр сагындыра
13-30 Родная земля
14-00 Эдера. (3-я серия)
15-00 Соотечественники
15-30 Природа у вас дома
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Мэктэп
17-00 К. Чуковский. «Муха-цокотуха»
17-40 Музыкаль NON-STOP
17-55 И. Мэхмутова. «Син бит минем бергенэм...»
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (4-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Истории золотых лихорадок
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Татарлар
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 КГТУ: путь к профессии
00-05 Приключения мага. (4-я серия)
01-00 Что сказал покойник. (10-я серия)
02-00 Видеоспорт
02-30 Истории золотых лихорадок

### 25 ИЮНЯ, ПЯТНИЦА

07-50 Жомга вэгазе
08-00 Хэерле итртэ!
09-45 Актуальный ислам
10-00 Доброе утро!
11-00 Концерт. (Оныта алмыйм)
11-45 КГТУ: путь к профессии
12-00 Мэдэният доньясында
13-00 Татар халык жырлары
13-20 Жомга вэгазе
13-30 Нэсыйхэт
14-00 Эдера. (4-я серия)
15-00 Реквизиты былой суеты
15-15 НЭП
15-30 Природа у вас дома
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Большая перемена-2010
17-25 Музыкаль тэнэфес
17-40 М. Гыйлэжев. «Алтынбэк хэм Су кызы»
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (5-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Прямая связь
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Адам белэн Хэва
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 КГТУ: путь к профессии
00-05 Дом, который построил Свифт
02-35 Джазовый перекресток
03-05 Миллионы

### 26 ИЮНЯ, СУББОТА

08-00 Татарстан хэбэрлэре
08-15 Новости Татарстана
08-30 Наркомания: в плену безумия
08-45 Реквизиты былой суеты
09-00 Sина Миннэн Sэлам
11-00 Выпускник-2010
11-30 Волшебник земноморья. (1-я и 2-я серии)
13-00 Мужское дело
13-30 Видеоспорт
14-00 Адымнар
14-30 Яшэсен театр!
15-00 Китап
15-30 Безнен эзлэр
18-00 Канун. Парламент. Жэмгыять
18-30 Секреты татарской кухни
19-00 КВН-2010
20-00 Мультфильм
20-30 Один день из жизни войны
21-00 Среда обитания
21-30 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
22-00 Татарстан. Атналык кузэту
22-30 Жырлыйк эле!
23-15 Елмай!
23-30 Новости Татарстана. В субботу вечером
00-00 Жандарм женится
01-40 Бои по правилам TNA
02-10 Ночной музыкальный канал
04-00 Свидетель
05-40 Музыкаль сэхифэ

### 27 ИЮНЯ, ВОСКРЕСЕНЬЕ

08-00 Татарстан. Атналык кузэту
08-30 Новости Татарстана. В субботу вечером
09-00 Истэлеккэ бер жыр булэк итэм
11-00 Секреты татарской кухни
11-30 Музыкаль тэнэфес
11-45 Мэктэп
12-00 Тамчы-шоу
12-30 Яшьлэр тукталышы
13-00 Мультфильмы
13-30 Автомобиль
14-00 Ватандашлар
14-30 Татарлар
15-00 Татар халык жырлары
15-30 Мэдэният доньясында
17-00 Экэмэт кэмит
17-40 Играем в Сабантуй
17-50 Актульный ислам
18-00 Закон. Парламент. Общество
18-30 Мужское дело
19-00 Путешествие со вкусом
20-00 Мультфильмы
20-20 Кладовая детского здоровья
20-30 7 дней
21-30 Экэмэт кэмит
22-00 Кэеф ничек?
22-45 Елмай!
23-00 Батырлар
23-20 Дорога без опасности
23-30 7 дней
00-30 Видеоспорт
01-00 Мальчики на пенсии
02-45 Нью-Йорк, Нью-Йорк
04-25 Ватандашлар

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ.
461600, г.Бугуруслан, ул.Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ

E-MAIL:tugan-iak-asekeevo@yandex.ru